МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.03.2016 Казан № 77

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерүче яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерүче яисә китерә ала торган кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 22 декабрендәге 650нче Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерүче яисә китерә ала торган кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 18 мартындагы УП-265 номерлы Указын үтәү йөзеннән **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерүче яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибен расларга (алга таба – Тәртип).

2. Кадрлар бүлегенә (В.Р.Садыйкова, Г.Ф.Сафина) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- әлеге боерыкка билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве үткәрү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юлларга;

- Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, һәм шулай ук хезмәт контрактлары төзегәндә башка затларны әлеге боерык белән таныштырырга;

- әлеге Тәртипне Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүмат стендына урнаштырырга.

3. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек бүлегенә (И.С.Сәгыйтов) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы рәсми сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегенә урнаштырырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
Боерыгы белән расланган
22.03.2016 № 77

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерүче яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип аларга карата эшкә алучы вәкиле Татарстан Республикасы икътисад министры (алга таба –министр) булган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәрләре, Министрлык) тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерүче яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү процедурасын регламентлаштыра.

2. Хәбәр граждан хезмәткәре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерүче яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында язмача хәбәр рәвешендә (алга таба – хәбәр) әлеге Тәртипкә Кушымта итеп китерелгән форма буенча тутырыла һәм министрга юллана.

3. Министр, алдан карау өчен, өч эш көне эчендә хәбәрне коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалауга җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) юллый.

4. Хәбәрне алдан карау барышында җаваплы затның хәбәр юллаган граждан хезмәткәреннән хәбәрдә күрсәтелгән хәлләргә аңлатма алырга, дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксындырган оешмаларга билгеләнгән тәртиптә гарызнамәләр юллау башлангычы белән чыгарга хокукы бар.

5. Хәбәрне алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Хәбәрне алдан карау барышында алынган хәбәр, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан ул алганнан соң җиде эш көне эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 4нче пунктында аталган гарызнамәләр җибәрелгән очракта хәбәрне алдан карау барышында алынган хәбәр, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан ул алганнан соң 45 көн эчендә Комиссия рәисенә җапшырыла. Әлеге срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, тик 30 көннән дә артыкка түгел.

7. Хәбәр, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан «Татарстан

Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгың 2016 елның 18 мартындагы 72нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә карала.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерүче яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибенә Кушымта

Татарстан Республикасы
икътисад министры
А.А.Здуновка

___________________________________
(вазыйфаның атамасы)

_______________________________________
_______________________________________
_______________________________________
(Ф.И.О. адрес, телефон номеры)

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерүче һәм китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында
**хәбәр**

Миндә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерүче һәм китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итәм (тиешлесенең астына сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булган хәлләр: _____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________

Үтәлешенә шәхси кызыксыну йогынты ясаучы яисә ясый ала торган вазыйфаи бурычлар: ____________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын кисәтү яисә җайлау буенча тәкъдим ителә торган чаралар:_____________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________

Әлеге хәбәрне тикшергәндә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайлау комиссиясе утырышында шәхсән үзем катнашырга ниятлим/ниятләмим (тиешлесенең астына сызарга)

| | | |
|---|---|---|
| ___________ | ___________ | ____________________________ |
| (дата) | (имза) | (имзаның расшифровкасы) |